| Республика Татарстан<br>Совет Альметьевского<br>сельского поселения<br>Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районы Әлмәт авыл<br>җирлеге советы |
| --- | --- |
| РЕШЕНИЕ<br>2018 ел 24 сентябрь | КАРАР<br>№ 22 |

"Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегетерриториясен төзекләндерү буенча норма һәм кагыйдәләрне раслау турында" 2018 елның 21 июнендәге 22 номерлы Әлмәт авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 463-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Җирлекләр, шәһәр округлары, шәһәр эчендәге районнар территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2017 елның 13 апрелендәге 711/пр номерлы боерыклары, Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Советы карар итте.

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү нормаларын һәм кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 21 июнендәге 22 номерлы Әлмәт авыл җирлеге Советы карарына, кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Әлмәт авылы, Солек авылы, Корман авылы торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе Д.А. Газизов

Әлмәт авыл җирлеге Советының
2018 елның 24 сентябрендәге
22 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү буенча норманы һәм кагыйдәләрне раслау турында» 2018 елның 21 июнендәге 9 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү

1. 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:
«3. Әлмәт авыл җирлеге территориясендә әлеге нормалар таләпләренең һәм төзекләндерү кагыйдәләренең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе башкара.

2. 10 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 10.6 пункт өстәргә:
«10.6. Торак зоналарда рөхсәт ителгән максималь массасы 3,5т дан артык булган һәм махсус билгеләнгән һәм (яисә) билге куелган урыннардан тыш йөк автомобильләре кую тыела.»

3. Түбәндәге эчтәлекле 11 бүлек белән тулыландырырга:
«11.1. Муниципаль берәмлектә терлекләрне тоту.
11.1.1. Этне урамда йөртү, өч айга кадәрге көчекләрне һәм махсус сумкага (контейнерга) яки аларны йөртүче кеше кулына кечкенә этләрне урамда йөртү очракларыннан тыш, йөгән (этне тотып торучы башка җайланма), муенчак һәм борынчак куллану белән башкарылырга тиеш. Әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән этнең муенчагында аның идентификация номеры күрсәтелгән булырга тиеш. Этне муенчаклы баудан башка урамда йөртү торак пунктлар чикләреннән читтә, шулай ук этләрне урамда йөртү өчен урыннарда рөхсәт ителә.
11.1.3. Җир кишәрлеге кулланган этләрнең хуҗалары этләрне ирекле көтүлектә бары тик яхшы киртәләнгән территориядә яки бәйлелектә генә тота ала. Эт барлыгы турында участокка кергәндә кисәтү язуы ясалырга тиеш.
11.1.4. Авыл хуҗалыгы хайваннарының муниципаль берәмлек территориясендә озата баручы затларсыз хәрәкәте тыела.
11.1.5. Авыл хуҗалыгы хайваннарын көтүне муниципаль берәмлек администрациясе махсус бүлеп биргән башлык яисә ул вәкаләт биргән зат күзәтүендә башкарырга тиеш. Үз белдеге белән терлек көтүе, үсентеләрне һәм яшел үсентеләрне юк итү яки зарарлау аркасында китерелгән зыян өчен терлек хуҗалары җаваплы.
11.1.6. Йорт кәҗәләре бары тик йорт яны территорияләре эчендәге утарларда гына яки көтүлектә хуҗалар күзәтүендә генә булырга тиеш.

11.1.7. Хайваннарны торак пункт урамнары буйлап куып җибәргәндә койма, яшел утыртмалар, клумбалар, хосусый йорт биләмәләре һәм оешмалар янында урнашкан клумбалар бозылуга юл куймаска.
11.1.8. Төп принциплар, йорт хайваннарын тоту шартлары, этләрне йөртү кагыйдәләре «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым

мәсьәләләре турында» 2014 елның 07 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә.

4. 9 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 9.10 пункт өстәргә:
«9.10. Реклама конструкцияләре һәм тышкы мәгълүмат чаралары Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә бертөрле үлчәмдәге шрифт белән рәсмиләштерелергә тиеш.».

5. 12 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 12.5 пункт өстәргә:
«12.5. Тиешсез сулыкларда, коенуны тыю турында язылган щитлар (аншлаглар) куелган урыннарда коену тыела.».

6. 13 п. 13.3. пп. 7 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«- юл һәм урам күрсәткечләре, географик атамалар һәм язулар, топографик билгеләр татар һәм рус телләрендә, шулай ук җирле халык мәнфәгатьләрен исәпкә алып башка телләрдә рәсмиләштерелергә тиеш.».